ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Арча районы Сарай-Чокырча тимер юл разъездын бетерү турында һәм «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 8 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Арча районының Сарай-Чокырча тимер юл разъездын бетерергә.

**2 статья**

«Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (I өлеш); 2008, № 12 (VII өлеш); 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 7; 2014, № 12 (IV өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2026, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:


1) 3 статьяның унынчы абзацында «, Сарай-Чокырча тимер юл разъезды» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Арча муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

## «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре

## **карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- жирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- жирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | | |
|---|---|---|
| 1 - 1 | - | Марий Эл Республикасы |
| 13(12) - 8(13) | - | Марий Эл Республикасы |
| 8(13) - 24(50) | - | Балтач муниципаль районы |
| 24(50) - 58(49) | - | Саба муниципаль районы |
| 58(49) - 66(48) | - | Теләче муниципаль районы |
| 66(48) - 64(46) | - | Питрәч муниципаль районы |
| 64(46) - 53(47) | - | Биектау муниципаль районы |
| 53(47) - 13(12) | - | Әтнә муниципаль районы |

«Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Арча шәһәре |
| 2 | Апаз авыл җирлеге |
| 3 | Кәче авыл җирлеге |
| 4 | Наласа авыл җирлеге |
| 5 | Яңа Кенәр авыл җирлеге |
| 6 | Яңа Кишет авыл җирлеге |
| 7 | Яңа Кырлай авыл җирлеге |
| 8 | Сеҗе авыл җирлеге |
| 9 | Урта Аты авыл җирлеге |
| 10 | Урта Курса авыл җирлеге |
| 11 | Иске Кырлай авыл җирлеге |
| 12 | Иске Чүриле авыл җирлеге |
| 13 | Ташкичү авыл җирлеге |
| 14 | Үрнәк авыл җирлеге |
| 15 | Утар Аты авыл җирлеге |
| 16 | Шушмабаш авыл җирлеге |
| 17 | Яңасала авыл җирлеге |

».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2026 ел, 19 июнь
№ 35-ТРЗ